| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2022 г. Казань № 759-237/кс-2022

«Пласт басымын саклап калу өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять өчен салкын су транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 20 октябрендәге 45-ПР номерлы Идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ҖЧҖ) өчен салкын су транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга әлеге карар кушымтасы нигезендә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе»

ЖЧЖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.12.2022 № 759-237/кс-2022
карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ЖЧЖ өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| 1 | Әлмәт муниципаль районы | | |
| | «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ЖЧЖ<br>башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән)<br><br>**су үткәрү челтәрләре:**<br>Автомобильчеләр урамы, 5;<br>Автомобильчеләр урамы, 9;<br>Автомобильчеләр урамы, 11;<br>Автомобильчеләр урамы, 15;<br><br>**канализация челтәрләре:**<br>Автомобильчеләр урамы, 5;<br>Автомобильчеләр урамы, 9;<br>Автомобильчеләр урамы, 11;<br>Автомобильчеләр урамы, 15. | 1,91 | 4,70 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге